КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 13 август г.Казань № 814

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Invest in Tatarstan» имидж кампаниясен тормышка ашыруга бәйле оешмаларның чыгымнарын каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибен раслау турында» 2021 ел, 21 июль, 637 нче карары белән расланган «Invest in Tatarstan» имидж кампаниясен тормышка ашыруга бәйле оешмаларның чыгымнарын каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

5 пунктта:

икенче абзацка «(2022 елда сайлауда катнашучының салымнар һәм җыемнар турындагы Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пеняләр, штрафлар, процентлар түләү буенча 300 мең сумнан артмаган башкарылмаган бурычы булырга мөмкин)» сүзләрен өстәргә;

түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«сайлап алуда катнашучы экстремистик эшчәнлеккә яки террорчылыкка катнашы булу турында мәгълүмат бирелгән оешмалар һәм физик затлар исемлегендә яисә массакүләм юк итү коралын таратуга катнашы булу турында мәгълүмат бирелгән оешмалар һәм физик затлар исемлегендә булмаска тиеш;

2022 елда сайлап алуда катнашучы Россия Федерациясенә, Россия Федерациясе гражданнарына яки Россия юридик затларына карата дусларча булмаган гамәлләр кылучы чит ил дәүләтләре тарафыннан сәяси яки икътисадый санкцияләр кертелү аркасында товарлар кайтарту, эшләр башкару, хезмәтләр күрсәтү турында төзелгән дәүләт (муниципаль) контрактларын үтәүдән баш тартуга һәм (яки) чит ил дәүләтләре, чит ил дәүләтләренең дәүләт берләшмәләре һәм (яки) союзлары һәм (яки) дәүләт (дәүләтара) учреждениеләре яки дәүләт берләшмәләре һәм (яки) союзлары

тарафыннан чикләү характерындагы чаралар кертелүгә бәйле рәвештә, намуссыз тәэмин итүчеләр (подрядчылар, башкаручылар) реестрында булмаска тиеш.»;

7 пунктта:

өченче абзацта «таныклыкның» сүзен «документның» сүзенә алмаштырырга;

дүртенче абзацка «(2022 елда сайлауда катнашучының салымнар һәм җыемнар турындагы Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча 300 мең сумнан артмаган башкарылмаган бурычы булырга мөмкин)» сүзләрен өстәргә;

8 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«сайлап алуны үткәрү сроклары, сайлап алуда катнашучылар заявкаларын кабул итә башлау яки сайлап алуны үткәрү турында белдерү урнаштырылган көннән соң килә торган 30 календарь көннән дә иртәрәк була алмаган заявкаларны кабул итү тәмамлану датасы (2022 елда тәкъдимнәрне (заявкаларны) кабул итү тәмамлану срогы сайлап алуны үткәрү турында белдерү урнаштырылган көннән соң килә торган 10 календарь көнгә кадәр кыскартылырга мөмкин);»

15 пунктта:

бишенче абзацка «(2022 елда килешүнең яңа шартларын килештерү тәртибе)» сүзләрен өстәргә;

җиденче абзац үз көчен югалткан дип танырга;

20 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«2022 елда субсидия бирү нәтиҗәләре күрсәткечләренә килешүдә билгеләгән срокларда ирешү мөмкинлеге булмауга китерә торган шартлар барлыкка килгән очракта, Агентлык, субсидия алучы белән килештереп, субсидия күләмен үзгәртмичә, субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү срокларын (әмма иң күбе 24 айга) озайту өлешендә килешүгә үзгәрешләр кертү турында карар кабул итәргә хокуклы. Субсидия күләмен үзгәртмичә, субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешү мөмкинлеге булмаган очракта, Агентлык субсидия бирү нәтиҗәсенең исәпләү зурлыгын киметү турында карар кабул итәргә хокуклы.»;

21 пунктта «нәтиҗәләре» сүзен «нәтиҗәнең мәгънәсе» сүзләренә алмаштырырга;

22 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«22. Субсидия алучы субсидия биргән очракта һәм субсидия бирү шартларын һәм тәртибен бозган очракта Татарстан Республикасы бюджетына субсидия алучы тарафыннан субсидия акчаларын кире кайтару, шул исәптән Агентлык һәм дәүләт финанс контроле органнары үткәргән тикшерүләр фактлары буенча, шулай ук субсидия бирү нәтиҗәләре күрсәткечләренә җитмәгәндә, Министрлыкның тиешле таләбе алынган көннән алып эш көннәрендә исәпләнә торган 30 көн эчендә гамәлгә ашырыла.»;

24 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«24. Агентлык субсидия алучылар тарафыннан субсидия бирү тәртибе һәм шартлары үтәлешен субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү өлешендә тикшерә.

Дәүләт финанс контроле органнары Россия Федерациясе Бюджет кодексының $268^1$ һәм $269^2$ статьялары нигезендә тикшерү үткәрә.

Субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешүне мониторинглау, Килешүдә билгеләнгән субсидия бирү нәтиҗәләре күрсәткечләренә ирешүдән һәм субсидия бирү нәтиҗәсен алу буенча тиешле чараны төгәлләү факты чагылдырыла торган вакыйгалардан (контроль нокта) чыгып, Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә һәм формалар буенча үткәрелә.»;

25 пунктта «максатчан һәм» сүзләрен төшереп калдырырга.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Юридик затларның конгресс-күргәзмә чараларын оештыру һәм үткәрү, конкурсларны оештыру-техник яктан тәэмин итү белән бәйле чыгымнарын каплауга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2021 ел, 23 август, 768 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 18 март, 247 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Юридик затларның конгресс-күргәзмә чараларын оештыру һәм үткәрү, конкурсларны оештыру-техник яктан тәэмин итү белән бәйле чыгымнарын каплауга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

5 пунктта:

икенче абзацка «(2022 елда сайлауда катнашучының салымнар һәм җыемнар турындагы Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча 300 мең сумнан артмаган башкарылмаган бурычы булырга мөмкин)» сүзләрен өстәргә;

түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«сайлап алуда катнашучы экстремистик эшчәнлеккә яки террорчылыкка катнашы булу турында мәгълүмат бирелгән оешмалар һәм физик затлар исемлегендә яисә массакүләм юк итү коралын таратуга катнашы булу турында мәгълүмат бирелгән оешмалар һәм физик затлар исемлегендә булмаска тиеш;

2022 елда сайлап алуда катнашучы Россия Федерациясенә, Россия Федерациясе гражданнарына яки Россия юридик затларына карата дусларча булмаган гамәлләр кылучы чит ил дәүләтләре тарафыннан сәяси яки икътисадый санкцияләр кертелү аркасында товарлар кайтарту, эшләр башкару, хезмәтләр күрсәтү турында төзелгән дәүләт (муниципаль) контрактларын үтәүдән баш тартуга һәм (яки) чит ил дәүләтләре, чит ил дәүләтләренең дәүләт берләшмәләре һәм (яки) союзлары һәм (яки) дәүләт (дәүләтара) учреждениеләре яки дәүләт берләшмәләре һәм (яки) союзлары тарафыннан чикләү характерындагы чаралар кертелүгә бәйле рәвештә, намуссыз тәэмин итүчеләр (подрядчылар, башкаручылар) реестрында булмаска тиеш.»;

7 пунктта:

өченче абзацта «таныклыкның» сүзен «документның» сүзенә алмаштырырга;

дүртенче абзацка «(2022 елда сайлауда катнашучының салымнар һәм җыемнар турындагы Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча 300 мең сумнан артмаган башкарылмаган бурычы булырга мөмкин)» сүзләрен өстәргә;

8 пунктның икенче абзацында «(2022 елда тәкъдимнәрне (заявкаларны) кабул итүне тәмамлау срогы сайлап алуны үткәрү турында игълан ителгән көннән соң килүче 10 календарь көнгә кадәр кыскартылырга мөмкин)» сүзләрен өстәргә;

15 пунктта:

бишенче абзацка «(2022 елда килешүнең яңа шартларын килештерү тәртибе)» сүзләрен өстәргә;

җиденче абзац үз көчен югалткан дип танырга;

19 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«2022 елда субсидия бирү нәтиҗәләре күрсәткечләренә килешүдә билгеләгән срокларда ирешү мөмкинлеге булмауга китерә торган шартлар барлыкка килгән очракта, Агентлык, субсидия алучы белән килештереп, субсидия күләмен үзгәртмичә, субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү срокларын (әмма иң күбе 24 айга) озайту өлешендә килешүгә үзгәрешләр кертү турында карар кабул итәргә хокуклы. Субсидия күләмен үзгәртмичә, субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешү мөмкинлеге булмаган очракта, Агентлык субсидия бирү нәтиҗәсенең исәпләү зурлыгын киметү турында карар кабул итәргә хокуклы.»;

20 пунктта «нәтиҗәләре» сүзен «нәтиҗәнең мәгънәсе» сүзләренә алмаштырырга;

21 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«21. Субсидия алучы субсидия биргән очракта һәм субсидия бирү шартларын һәм тәртибен бозган очракта Татарстан Республикасы бюджетына субсидия алучы тарафыннан субсидия акчаларын кире кайтару, шул исәптән Агентлык һәм дәүләт финанс контроле органнары үткәргән тикшерүләр фактлары буенча, шулай ук субсидия бирү нәтиҗәләре күрсәткечләренә җитмәгәндә, Министрлыкның тиешле таләбе алынган көннән алып эш көннәрендә исәпләнә торган 30 көн эчендә гамәлгә ашырыла.»;

23 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«23. Агентлык субсидия алучылар тарафыннан субсидия бирү тәртибе һәм шартлары үтәлешен субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү өлешендә тикшерә.

Дәүләт финанс контроле органнары Россия Федерациясе Бюджет кодексының 268[1] һәм 269[2] статьялары нигезендә тикшерү үткәрә.

Субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешүне мониторинглау, Килешүдә билгеләнгән субсидия бирү нәтиҗәләре күрсәткечләренә ирешүдән һәм субсидия бирү нәтиҗәсен алу буенча тиешле чараны тәгәлләү факты чагылдырыла торган вакыйгалардан (контроль нокта) чыгып, Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә һәм формалар буенча үткәрелә.»;

24 пунктта «максатчан һәм» сүзләрен төшереп калдырырга.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Invest in Tatarstan» имидж кампаниясен тормышка ашыруга бәйле оешмаларның чыгымнарын каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибен раслау турында» 2021 ел, 21 июль, 637 нче карары белән расланган «Invest in Tatarstan» имидж кампаниясен тормышка ашыруга бәйле оешмаларның чыгымнарын каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибенең 5 пунктындагы өченче абзацы һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Юридик затларның конгресс-күргәзмә чараларын оештыру һәм үткәрү, конкурсларны оештыру-техник яктан тәэмин итү белән бәйле чыгымнарын каплауга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау

турында» 2021 ел, 23 август, 768 нче карары белән расланган Юридик затларның конгресс-күргәзмә чараларын оештыру һәм үткәрү, конкурсларны оештыру-техник яктан тәэмин итү белән бәйле чыгымнарын каплауга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенең 5 пунктындагы өченче абзацы гамәлен 2023 елның 1 гыйнварына кадәр туктатып торырга.

4. Бу карар (әлеге карарның 2023 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә торган 1 пунктындагы егерме өченче абзацыннан һәм 2 пунктындагы егерме икенче абзацыннан тыш) рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин